

# Тамчы

МБББУ "Икенче санлы Җәлил урта гомуми белем бирү мәктәбе"

№ 6 (66), февраль, 2016-2017 нче уку елы

# 21 нче февраль - Халыкара туган тел коне

# 21 февраля— Международный день родного языка

## ТУГАН ТЕЛ КӨНЕНДӘ - ТУКАЙ ТЕЛЕНДӘ

2017 нче елның 18 нче февралендә якташ язучыбыз, Россиянең һәм Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, Гаяз Исхакый премиясе лауреаты Рәфкать Кәрамигә 75 яшь тулды. Шул уңайдан мәктәбебездә "Кәрами укулары" оештырылды. Укуларның төп максаты Сарман ягы төбәге әдипләренең иҗади мирасын өйрәнү, пропагандалау иде. Укулар Татарстанның дистәдән артык районында теләктәшлек тапты. Аның беренче турына 200 ләп эш кабул ителде. Финал өлешендә 89 мөгаллим һәм укучы чыгыш ясады.

Укуларны оештыруда Татарстан Язучылар берлеге, Яр Чаллы дәүләт педагогика университетының ярдәме искиткеч зур булды. Укучылар тарафыннан җибәрелгән һәр эш җентекләп тикшерелде, анализланды, бәяләнде.

Барлык кунакларны мәктәбебез директоры Р.К.Сәетгәраева сәламләде. Ул белем йортының тарихы, укучыларның һәм укытучыларның уртак матур нәтиҗәләре белән таныштырды. Юбилярны һәм фәнни бәйгедә катнашучыларны котларга Сарман муниципаль районы җитәкчелеге, Җәлил бистәсе башлыгы урынбасары, мәгариф бүлеге белгечләре, "Җәлил чаткылары" әдәби иҗат берләшмәсе әгъзалары килде. Алар да җылы, матур теләкләрен җиткерделәр. Соңыннан сүзне әдип туып-үскән Рангазар авылы делегациясе алды.

Күренекле якташыбызның шундый юллары бар: "Юкка гына әйтмәгәннәр: малын жуйган жиде ел елар, иленнән аерылган –гомер буе. Дөнья киң. Адәм баласы йөремсәк. Ул кай тарафка гына барып чыкмый. Әмма ул һәрчак кендек каны тамган җирен – изге туган ягын сагынып кайта. Чөнки аның бәхете – туган илендә, туган җирендә." Рәфкать агага да үзенең авылдашларының эчкерсез рәхмәтләрен ишетү бик рәхәт булгандыр. Рангазарлылар барыбызга да әнә шундый күңел күтәренкелеге бирделәр, бәйрәмгә күңел җылылыгы, ямь өстәделәр.

**Ландыш Камил кызы Шәйдуллина**

## ТАНЫШ БУЛЫЙК: РӘФКАТЬ КӘРАМИ



Язучы Рәфкать Кәрами 1942 елның 18 февралендә Татарстанның Сарман районы Рангазар авылында колхозчы гаиләсендә туган. Авылда җидееллык мәктәпне, 1959 елда Алабуга мәдәният-агарту техникумын тәмамлагач, ул берникадәр вакыт район Мәдәният йортында баянчы, аннан Түбән Әхмәт авылында клуб мөдире булып эшли.

Берничә ел Әлмәт якларында, нефть производствосында хезмәт куя. Армия сафларына алынып, өч ел Хәрби диңгез флотында, яр буе гаскәрендә хезмәт итә. 1964-1977 елларда ул Казанда "Оргсинтез" заводын коруда катнаша: башта электрик булып эшли , соңыннан "Казанхимстрой" тресты 5нче төзү идарәсендә профком рәисе була. 1970 елда, төп хезмәтеннән аерылмыйча укып, Казан дәүләт университетының тарих бүлеген тәмамлый.

Шушы чорда ул иҗат итә башлый, 1967 елда үзенең "Дүрт кешелек каюта" дигән беренче повестен тәмамлый. 1978 елда ул матбугатта"Очар кошлар белән янәшә" исемле күләмле әсәрен бастыра. Трилогиянең икенче кисәге – "Ашкыну" – 1982 елда, өченче китабы – "Чыныгу" – 1985 елда, ә трилогия булып 1999 елда "Очар кошлар белән янәшә" исеме астында басылып чыга.

Аның "Сагышлы кояш" (1983), "Ындыр тулы кибән" (1983), "Мәхәббәт бураннары" (1985), "Йөрәгемне ут алган" (1987) повестьлары кешеләр арасындагы катлаулы мөнәсәбәтләр турында. 1992 елда язучының "Ындыр тулы кибән" дигән зур җыентыгы басылып чыга. Хикәяләре аның "Өзелгән чәчәк" исемле җыентыгында (2002) урын алган. Аерым хикәяләре рус, әзербайҗан, кыргыз, хакас, казак, мари, мордва, чуаш телләренә дә тәрҗемә ителгән. 1982 елда Минзәлә татар дәүләт драма театры Р. Кәраминең "Яратуың чынмы?" исемле драма әсәрен сәхнәгә куйды. Ә "Каргышлы этаплар" романы өчен Р. Кәрами 1999 елда Татарстан Язучылар берлегенең Гаяз Исхакый исемендәге бүләге бирелә.

## Конференция көндәлеге:  секцияләрдән хәбәрләр

**“Очар кошлар белән янәшә”** дип аталган секциядә укучылар үзләренең Р.Кәрами иҗаты буенча булган фәнни-тикшеренү эшләрен якладылар. Секция белән Яр Чаллы дәүләт педагогика университеты профессоры, филология фәннәре докторы Шәрипов Әнвәр Мәгъдәнур улы җитәкчелек итте. Ул укучыларның әзерләгенә бәя биргәндә, аларның әсәрләрне җентекләп өйрәнгән булуы турында сөйләде, кыю фикерләр яңгыраганына басым ясады. Бу секциядә иң югары баскычка Сарман мәктәбенең 10 нчы сыйныф укучысы Нигъмәтуллина Гөлшат Ришат кызы күтәрелде.



Безнең мәктәп укучылары бу секциядә уңышлы чыгыш ясадылар. 9 нчы в сыйныфыннан Бакирова Эльмира белән Кәримова Гөлшат 2 нче урынны яуладылар. Алар әдипнең әсәрләрендәге әхлак проблемасын өйрәнгәннәр. Автор укучысына нинди киңәш бирергә теләве турында чыгыш ясадылар. 7нче б сыйныфы укучысы Багаува Алиянең “Рәфкать Кәраминең сатира һәм юмор осталыгы”дип аталган эше 3 нче урынга лаек булды.

### “Каргышлы этаплар” секциясе

Сталин репрессиясенә эләгеп, гөнаһсыз рәнҗетелгән туганнар, якташларыбызның тормышларын өйрәнү тәҗрибәсе, буыннан-буынга килгән истәлекләр, архив документларына нигезләнгән иншалар бәйгесенә килгән эшләр Яр Чаллы дәүләт педагогика университеты доценты, филология фәннәре кандидаты Мөхиярова Рәзинә Хәйбрахман кызы тарафыннан тикшерелде. Укучылар чыгышын бәяләүдә “Җәлил чаткылары” әдәби иҗат берләшмәсе әгъзалары да катнашты. Шагыйрә иҗади эшләрдән бик канәгать калуын яшермәде. “Тетрәнеп, дулкынланып укыдым. Аяныч хәлләрне күңелем аша үткәрдем. Бу хәлләрнең кабатлану мөмкинлеге булу җанны өшетә,” - диде ул. Укучыларның эшләре шагыйрә галимә шигъри юллар тудыруга этәргән. Аның бар чыгышы шигырьләре белән үрелеп барды. Шулай да иң куандырганы укучыларга, аеруча бу секциянең җиңүчесе - Сарман гимназиясе укучысы Сөләйман Мөхәммәтҗановка биргән бәясе булды. “Бу эш белән бер курыкмыйча рәсәйкүләм фәнни бәйгеләргә барырлык,” - диде галимә.



2 нче секциядә мәктәбебезнең 8 нче б сыйныфы укучысы Салихова Айсылу уңышлы чыгыш ясады.



Иң күп эш “Мәңге шулай тыныч булсын авылым таңнары” дип аталган секциягә кабул ителде. Бу секциянең җаваплы оештыручысы югары категорияле башлангыч сыйныфлар укытучысы Ләйлә Мияссәрова сүзләре белән әйтсәк, без бөтен Татарстанның авыл һәм бистәләре белән танышырлык презентацияләр кабул иттек. Эшләр шундый кызыклы, мавыктыргыч, матур иде. Катнашучыларның эшләре яшьләре буенча 3 төркемгә бүлеп тикшерелде. Һәр төркемдә өч эш авторы иң зур бәя алды. Бу - Зиннәтуллина Диана (Җәлил гимназиясе, 2нче сыйныф), Салахова Лилия (Азнакай районы Актүбә бистәсе, 3 нчы сыйныф), Фомина Эльвина (Әлмәт районы Иске Михайловка мәктәбе, 5 сыйныф). Бәйгенең барлык җиңүчеләре, ә алар 18 укучы иде, бистә музеенда булдылар, герой шагыйрь тормышы, туган як тарихы белән бәйле экспозицияләрне карадылар.

**Шеф редактор**: Шайдуллина Ландыш Камиловна

**Редколлегия**: Закиева Азалия, Мухаметгалиева Гузель, Насибуллин Данияр(6В)

**Приём материала** (статей, рассказов, стихов, рисунков и др.) осуществляется через членов редколлегии или шеф-редактора (307 кабинет).